| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы**

№ 3 «22»февраль 2024 ел

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2023 елның 10 октябрендәге №1 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №518-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары үткәрелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 октябрендәге №1 «Җир салымы турында» карарының 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 17) пунктчасы белән тулыландырырга:

«17) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары карамагындагы башка җир кишәрлекләренә карата 0,01 %».

2.Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы,
Тауасты Байлар авыл җирлеге Советы рәисе З.С.Гәрәева

ОГРН 1021605552792 Совет ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО сельского поселения 1628002996